| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.02.2017 № 74

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 3 мартында теркәлгән, №3838

2017 елда өлкән яшьтәге гражданинга һәм аны үз гаиләсенә сыендырырга теләүче кандидатка психологик әзерлек үткәрү тәртибен раслау турында

“Өлкән яшьтәге кешене үз канаты астына сыендыручы гаилә” пилот проектын тормышка ашыру турында” 31.08.2016 ел, № 604 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган, үз акылындагы өлкән яшьтәге гражданнарны үз канаты астына сыендыручы гаиләләр булдыру тәртибе һәм аларны булдыру шартлары турында нигезләмәнең 2.7 пунктын тормышка ашыру максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. 2017 елда өлкән яшьтәге гражданинга һәм аны үз гаиләсенә сыендырырга теләүче кандидатка психологик әзерлек үткәрү тәртибен (кушымта итеп бирелә) (алга таба – Тәртип) расларга.

2. “Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика мәгълүмат-методика үзәге” социаль хезмәт күрсәтү дәүләт казна учреждениесенә Татарстан Республикасында

яшәүчеләргә комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре тарафыннан өлкән яшьтәге гражданнарга һәм аларны үз гаиләсенә сыендырырга теләүче кандидатларга психологик әзерлек үткәрүнең методик ягын хәл итәргә.

3. Татарстан Республикасында яшәүчеләргә комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре директорларына өлкән яшьтәге гражданнарга һәм аларны үз гаиләсенә сыендырырга теләүче кандидатларга психологик әзерлек үткәрүне оештыруда бу боерык белән расланган Тәртипкә таянырга.

4.Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Ю.И.Абдреевага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13 февраль, 2017 ел, № 74 боерыгы белән расланды

2017 елда өлкән яшьтәге гражданинга һәм аны үз гаиләсенә сыендырырга теләүче кандидатка психологик әзерлек үткәрү тәртибе

1. 2017 елда өлкән яшьтәге гражданинга һәм аны үз гаиләсенә сыендырырга теләүче кандидатка психологик әзерлек үткәрүнең бу Тәртибе (алга таба – Тәртип) “Өлкән яшьтәге кешене үз канаты астына сыендыручы гаилә” пилот проектын тормышка ашыру турында” 31.08.2016 ел, № 604 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Стационар социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган, үз акылындагы өлкән яшьтәге гражданнарны үз канаты астына сыендыручы гаиләләр булдыру тәртибе һәм аларны булдыру шартлары турында нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) тормышка ашыру максатыннан чыгып эшләнде.

2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр Нигезләмәдә ничек билгеләнсә, шундый ук мәгънәдә кулланыла.

3. Бу Тәртип өлкән яшьтәге гражданинга һәм кандидатка психологик әзерлек үткәрү кагыйдәләрен билгели.

4. Өлкән яшьтәге гражданинга һәм кандидатка психологик әзерлек бушлай үткәрелә.

5. Татарстан Республикасында яшәүчеләргә комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге (алга таба – КЦСОН), өлкән яшьтәге гражданинга һәм кандидатка психологик әзерлек үткәрү максатыннан чыгып, өлкән яшьтәге гражданинны гаиләгә сыендыру турында өлкән яшьтәге гражданин белән кандидат арасында килешү төзү хакында карар (алга таба – гаиләгә сыендыру турында килешү төзү хакында карар) кабул ителгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча өлкән яшьтәге гражданинга һәм

кандидатка үзләренә психологик әзерлек үткәрүнең датасы, вакыты һәм урыны турында язмача хәбәр итә.

6. Өлкән яшьтәге гражданинга һәм кандидатка психологик әзерлек Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган өлкән яшьтәге гражданинга һәм кандидатка психологик әзерлек үткәрү программасы (алга таба - Программа) нигезендә гаиләгә сыендыру турында килешү төзү турында КЦСОН карары кабул ителгәннән соң 10 көн узгач үткәрелә.

7. Өлкән яшьтәге гражданинга һәм кандидатка психологик әзерлек үткәрү гаиләгә сыендыру турында килешү төзү турында карар кабул иткән КЦСОН тарафыннан хәл ителә.

Психологик әзерлекнең дәвамлылыгы:

өлкән яшьтәге гражданин өчен 7 сәгать тәшкил итә;

кандидат өчен 10 сәгать тәшкил итә.

8. Психологик әзерлек юнәлдерелә:

кандидатка өлкән яшьтәге гражданинны үз гаиләсенә сыендырырга (алга таба – сыендыручы гаилә) ни дәрәҗәдә әзер булуын билгеләргә, гаиләсенә сыендырган очракта килеп чыгу ихтималы булган кыенлыклар һәм проблемаларны, кандидатның җаваплылыгын аңлауга ярдәм итү;

өлкән яшьтәге гражданинга үзен сыендыручы гаиләдә яшәргә ни дәрәҗәдә әзер булуын билгеләргә, сыендыручы гаиләдә яшәгәндә килеп чыгу ихтималы булган кыенлыклар һәм проблемаларны аңлауга ярдәм итү;

кандидатта өлкән яшьтәге гражданинның психологиясенә кагылышлы белемнәр булдыру;

кандидатны һәм өлкән яшьтәге гражданинны, сыендыручы гаилә булдырылган очракта, җайлашу чорының үзенчәлекләре белән таныштыру;

кандидатны өлкән яшьтәге гражданинны карау, тормыштагы төп ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм иминлеген тәэмин итү үзенчәлекләре белән таныштыру;

кандидатны һәм өлкән яшьтәге гражданинны сыендыручы гаиләдә мөнәсәбәтләрнең тотрыклылыгын билгеләүче психологик факторлар белән таныштыру;

кандидатны һәм өлкән яшьтәге гражданинны гамәлдәге профессиональ ярдәм һәм психологик ярдәм формалары белән таныштыру.

9. Психологик әзерлек кандидат һәм өлкән яшьтәге гражданин белән уртак әңгәмә үткәрү, шулай ук кандидат һәм өлкән яшьтәге гражданин белән шәхсән әңгәмә үткәрү (шул исәптән психологик әзерлек йомгаклары буенча фикер алышуны үз эченә алган) нигезендә тәгәлләнә.

10. Өлкән яшьтәге гражданинга (кандидатка) психологик әзерлек үткәрү нәтиҗәләре буенча КЦСОН аларның һәркайсына, бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендәге форма буенча, сыендыручы гаилә булдырырга теләүче өлкән яшьтәге гражданинга (кандидатка) психологик әзерлек үткәрү турында белешмә (алга таба – белешмә) рәсмиләштерә, белешмәләрне өлкән яшьтәге гражданинның һәм кандидатның шәхси делосына урнаштыра.

11. КЦСОН, бу Тәртипкә №2 кушымта нигезендәге форма буенча, белешмәләрне сыендыручы гаилә булдырырга теләүче өлкән яшьтәге гражданинга (кандидатка) психологик әзерлек үткәрү турында белешмәләрне теркәү журналында терки.

12. КЦСОН өлкән яшьтәге гражданинга (кандидатка) психологик әзерлек үткәрү барышында алынган персональ мәгълүматларның яшеренлеген тәэмин итә.

2017 елда өлкән яшьтәге гражданинга һәм аны үз гаиләсенә сыендырырга теләүче кандидатка психологик әзерлек үткәрү тәртибенә №1 кушымта

Форма

Сыендыручы гаилә булдырырга теләүче өлкән яшьтәге гражданинның (кандидатның) психологик әзерлек үтүе турында белешмә №_____ от __________2017

______________________________________________________________,
*(сыендыручы гаилә булдырырга теләүче гражданинның (кандидатның) ф.и.о.)*

Психологик әзерлек үтү чоры:
«_____»____________201____елдан «_____»___________201____елга кадәр

Психологик әзерлек йомгаклары:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Психологик әзерлек
үткәргән затның имзасы ___________________

Психологик әзерлек

үткәргән белгечнең имзасы:

___________________________ ________________________ ________________

*(вазыйфасы)(Ф.И.О.)(имзасы)*

Директор _________________________________________________________________

*( учреждение атамасы)*

____________________________________ ________________________________

*(Ф.И.О.)* *(имза)*

М.У.

2017 елда өлкән яшьтәге гражданинга һәм аны үз гаиләсенә сыендырырга теләүче кандидатка психологик әзерлек үткәрү тәртибенә №2 кушымта

Форма

Сыендыручы гаилә булдырырга теләүче өлкән яшьтәге гражданинга (кандидатка) психологик әзерлек үткәрү турында белешмәләрне теркәү журналы

| Nп/п | Психологик әзерлек үткән гражданинның (кандидатның) Ф.И.О. | Туу датасы | Әзерлек үтү чоры | Белешмә № һәм аны рәсмиләштерү датасы | Психологик әзерлек үткәргән белгечнең Ф.И.О. һәм вазыйфасы |
|---|---|---|---|---|---|
| *1* | *2* | *3* | *4* | *5* | *6* |
| | | | | | |